**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1221**
**16.03.2020**

2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан чыгарыла торган «Жилой Квартал Челны» газетасының 1 (бер) данәсенең бәясенә тарифны, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 50,00 (илле) сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев